ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№353 от «19» 10 2020 г.

2020 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган keremнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының «Мамадыш муниципаль районында социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының исәп нормасы һәм торак урыны бирү нормасы турында» 2007 елның 14 февралендәге 173 номерлы карары, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2020 елның 07 мартындагы 44 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» бәяләмәсе нигезендә Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2020 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Һәр гражданга туры килә торган керем күләме һәм гражданнар милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы кеременең иң чик күләме:

- ялгыз яшәүче кеше өчен - 820 479 сум;
- ике кешелек гаилә өчен - 1 044 246 сум;
- өч кешелек гаилә өчен - 1 342 602 сум;
- дүрт кешелек гаилә өчен - 17 901 36 сум;
- биш кешелек гаилә өчен - 2 237 670 сум;
- алты кешелек гаилә өчен - 2 685 204 сум;
- җиде кешелек гаилә өчен - 3 132 738 сум;
- сигез кешелек гаилә өчен - 3 580 272 сум;

0000010648

1.2 гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:
- ялгыз яшәүче граждан өчен - 22 976,63 сум;
- ике кешелек гаилә өчен - 14621, 49 сум;
- өч кешелек һәм аннан да күбрәк кеше өчен - 12 548,53сум.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенең торакны исәпкә алу һәм бүлү секторына әлеге карарда күрсәтелгән максималь чик күрсәткечләрен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә куелганда кулланырга.

3.Әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
19.10.2020 ел 333 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

# МЕТОДИКА
## 2020 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмен билгеләү
# МЕТОДИКАСЫ

1. Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС РЦ

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урынны сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе.

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2020 елның 07 мартындагы 44 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» бәяләмәсе нигезендә 2020 елның 1 кварталында Мамадыш муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 24863 сум тәшкил итә.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 24863 х 33 = 820 479 сум

б) ике кешелек гаиләгә:

СЖ = 24863 х 42 = 1 044 246 сум

в) өч кешелек гаиләгә:

СЖ = 24863х 18 х 3 = 1 342 602 сум

г) дүрт кешелек гаиләгә:

СЖ = 24863х 18 х 4 = 1 790 136 сум

д) биш кешелек гаиләгә:

СЖ = 24863 х 18 х 5 = 2 237 670 сум

е) алты кешелек гаиләгә:

СЖ = 24863 х 18 х 6 = 2 685 204 сум

ж) җиде кешелек гаиләгә:

СЖ = 24863 х 18 х 7 = 3 132 738 сум

3) сигез кешелек гаиләгә:

СЖ = 24863 х 18 х 8 = 3 580 272 сум

2. Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләмен алуның иң чик күрсәткече:

**ПД = 0,7 х СЖ ПС / (1 - (1 + ПС) -КП / (0,3 х РС), монда**

ПД - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик әһәмияте;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер айга процент ставкасы (унарлы вакланма), (коммерция кредит оешмаларының ачык чыганакларыннан мәгълүматлар буенча) елына 12 %, ягъни аена 12/12/100 = 0,01);

КП - кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

Гражданның һәр гаилә әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган иң чик уртача айлык җыелма керем исәп – хисабы

Табл. №1

| НП - торак урыны нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х НП РЦ) (сум). | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше). | РЦ - торак урынның 1 кв. метрының базар бәясе (сум). | ПС - кредит буенча бер ай эчендә процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ае) | Кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык кереме белән нисбәте | Керемнең икеле әһәмияте (сум) (кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 24863 | 12/12/100= 0,01 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 33 | 820479 | 1 | 24863 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,3 | 22976,63 |
| 42 | 1044246 | 2 | 24863 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,6 | 14621,49 |
| 54 | 1342602 | 3 | 24863 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,9 | 12548,53 |
| 72 | 1790136 | 4 | 24863 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,2 | 12548,53 |
| 90 | 2237670 | 5 | 24863 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,5 | 12548,53 |
| 108 | 2685204 | 6 | 24863 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,8 | 12548,53 |
| 126 | 3132738 | 7 | 24863 | 0,01 | 180 | 0,7 | 2,1 | 12548,53 |
| 144 | 3580272 | 8 | 24863 | 0,01 | 180 | 0,7 | 2,4 | 12548,53 |

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик кыйммәтен исәпләү

1. Ялгыз яшәүче кеше өчен:
ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,3 х РС) = 0,7 х 820 479 х 0,01 / (1 - 1/1,01180) /0,3 х 1) = 57443,353/1-0,16678/0,3 = 5743,353/0,83166/0,3= 22 976,63

2. Ике кешелек гаиләгә:
ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,3 х РС) = 0,7 х 820 479 х 0,01 / (1 - 1/1,01180)/(0,3 х 2) = 7309,722/1-0,16678/0,6 = 7309,722/0,83166/0,6= 14 621, 49

3. Өч кешедән торган гаиләгә һәм аннан да күбрәккә:
ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)-кп) = 0,7 х 1342602 х0,01 / (1 -1/1,01180) / (0,3 х 3) = 7309,722/1-0,678/0,9 = 9398,214/0,83166/0,9= 12 548,53